# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлегенең Сарман авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 27 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман авылында гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман авылы территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан (студентлар, Кораллы Көчләр сафларында хезмәт итүче затлар), I һәм II төркем инвалидлардан һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнарданнар, хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Сарман авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын сатып алу (янгын җиңе, гидрантлар, янгын гидрантлары күрсәткечләре);
- Сарман авылы В.Терешкова урамы буенча тротуарларын урнаштыру;
- бүләкләр алу һәм Сарман авылында Сабантуй, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, юбилярларны котлау;
- Сарман авылында йорт номерларын әзерләү һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
- Сарман авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Сарман авылында коры агачларны кисү (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сарман авылындагы күп фатирлы йортлар ишегалларын һәм урамнарны төзекләндерү (иске хуҗалык корылмаларын сүтү, коймалар урнаштыру, балалар өчен уен мәйданчыклары һәм МАФлар сатып алу);
- паркларны яшелләндерү һәм карап тоту (печән чабу, инвентарь һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу) Сарман авылы;

- тракторга хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, өстәмә җиһазлар, запчастьләр сатып алу, хезмәт өчен түләү);
- Сарман авылы зиратын карау (зиратны карау, инструментлар алу,).

3. Әлеге карарны Сарман авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман авылы башкарма комитеты
җитәкчесе
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.И.Сахуриев